РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

---

РЕШЕНИЕ

КАРАР

№ 75

2019 елның 20 декабре

Түбән Кама муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына район бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 9 һәм 142.4 статьялары, Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 30 статьясы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына район бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга (кушымта).

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль-икътисадый үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре һәм муниципаль милек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы

А.Р.Метшин

Түбән Кама муниципаль районы
Советының
2019 елның 20 декабрендәге
75 номерлы карарына
кушымта

Түбән Кама муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына район бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе

## 1. Гомуми нигезләмәләр

Түбән Кама муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына район бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе (алга таба – Тәртип) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 9 һәм 142.4 статьялары нигезендә эшләнде һәм Түбән Кама муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү очракларын һәм тәртибен билгели.

## 2. Башка бюджетара трансфертлар бирү очраклары

Түбән Кама муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына район бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар түбәндәге очракларда бирелергә мөмкин:

1) төзелгән килешүләр нигезендә җирлекләр дәрәҗәсенә тапшырганда. муниципаль районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен;

2) гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрен хәл итү өчен;

3) көтелмәгән чыгымнарны, шул исәптән авария-торгызу эшләрен һәм табигый бәла-казалар һәм башка гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетерүгә бәйле башка чараларны финанс белән тәэмин итүгә, шулай ук Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитеты раслаган резерв фондының бюджет ассигнованиеләреннән файдалану тәртибендә каралган башка чараларга (алга таба – «район башкарма комитеты»);

4) җирлекләр бюджетларына бирү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан бюджетара трансфертлар алынган очракта;

5) бюджет турында карарда каралган башка максатларга.

## 3. Башка бюджетара трансфертларны бирү шартлары һәм тәртибе

1. Бюджетара трансфертлар бюджет ассигнованиеләре һәм күрсәтелгән максатларга бюджет турындагы карарда каралган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

2. Әлеге карар нигезендә бирелә торган бюджет ассигнованиеләрен төп бүлүче булып, Түбән Кама муниципаль районының бюджет һәм финанслар департаменты (алга таба – «финанс органы») тора.

3. Түбән Кама муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына бюджетара трансфертларны бүлү бюджет турындагы карар белән раслана.

4. Бюджетара трансфертларның максатлары, шартлары һәм тәртибе район башкарма комитеты һәм Түбән Кама муниципаль районы җирлегенең башкарма комитеты (алга таба – «җирлек башкарма комитеты») арасында төзелгән килешүләр белән билгеләнә.

5. Әлеге Тәртипнең 2 бүлегендәге 1 пункты нигезендә бюджетара трансфертлар бирү «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 пунктында каралган тәртиптә Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы җирлекләренең җирле үзидарә органнары белән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турындагы килешүләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

6. Әлеге Тәртипнең 2 бүлегендәге 2-4 пунктлары нигезендә бюджетара трансфертлар бирү түбәндәге тәртиптә гамәлгә ашырыла:

6.1 Башка бюджетара трансфертлар район башкарма комитеты карары нигезендә һәм район башкарма комитеты һәм җирлек башкарма комитеты (алга таба – «килешү») төзегән килешү нигезендә бирелә.

6.2 Башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы мәсьәләне карау өчен җирлек башкарма комитеты җитәкчесе район башкарма комитеты җитәкчесенә аларны файдаланырга теләгән максатларын һәм соратып алына торган сумманы раслый торган исәп-хисапларны күрсәтеп, финанс чаралары бүлеп бирү турында мотивлаштырылган мөрәҗәгать юллый.

6.3 Җирлек башкарма комитеты җитәкчесенең җирлек бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы мөрәҗәгате район башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан мөрәҗәгать алынганнан соң 10 көн эчендә карала. Башка бюджетара трансфертларны бирү турындагы карар, финанс органы фикерен исәпкә алып, Түбән Кама муниципаль районы башлыгы белән килештереп кабул ителә.

Финанс органы район башкарма комитетының аерым җирлеккә башка бюджетара трансфертлар бүлеп бирү турындагы карарын һәм җирлек бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы килешүне рәсмиләштерә.

6.4 Җыелма бюджет язмасына үзгәрешләр керткәннән соң, район башкарма комитеты карары һәм килешү нигезендә финанс органы авыл җирлеге бюджетына бюджет ассигнованиеләрен җирле бюджетлар үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен ачылган Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең территориаль органы счетларына күчерүне башкара.

7. Башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, җирлек башкарма комитеты җитәкчесенә карар кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә, финанс органы тарафыннан әзерләнгән мотивлаштырылган язмача баш тарту җибәрелә.

4. Башка бюджетара трансфертлардан файдалануга җаваплылык һәм контроль

1. Бюджетара трансфертларның максатларын яки шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә район башкарма комитетының язма таләбе буенча биш банк көне эчендә район бюджеты кеременә күчерелергә тиеш.

2. Бюджетара трансфертлар бирү елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына кадәр файдаланылмый калган бюджетара трансфертлар калдыгы, Россия Федерациясе Бюджет кодексы билгеләгән таләпләр нигезендә, район бюджеты керемена кире кайтарылырга тиеш.

3. Башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын финанс органы контрольдә тота. Контроль районның финанс органына финанс чараларыннан файдалану турында хисап бирү юлы белән башкарыла. Отчетларны тапшыру вакыты һәм формасы килешүдә билгеләнә.

4. Килешүдә каралмаган максатларга башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелгән акчаларны тоту рөхсәт ителми.

5. Башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланмаган өчен җирлекләрнең җирле үзидарә органнары Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы урынбасары Э.Р.Долотказина